ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.09.2024 ел Баулы шәһәре № 119

2025 елга гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру хезмәте күрсәтү бәясе нормативлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыруны финанслау нормативларын исәпләү буенча Методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2010 елның 5 июлендәге 545 номерлы карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1.Кушымталарны расларга:

- 2025 елга гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру хезмәте күрсәтү бәясе нормативлары (1-нче кушымта);

- Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә (2-нче кушымта).

2. Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны әлеге карарның 1 пунктында расланган балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары нигезендә гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров

1-нче номерлы кушымта

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 10 сентябрендәге
119 номерлы карары белән
РАСЛАНГАННАР

2025 елга, махсус
балаларны йөртү өчен билгеләнгән автобуслар белән, укучыларны йөртүне оештыру
буенча хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары

| Автотранспорт чарасының модель атамасы | Ике ставкалы нормативның күләме | |
|---|---|---|
| | Бер автотранспорт чарасына ставка, бер елга сумнарда | Бер автотранспорт чарасының бер чакрым йөрешенә ставка, бер елга сумнарда |
| КАВЗ | 1 128 838,81 | 24,40 |
| ПАЗ | 1 129 096,31 | 24,56 |
| ГАЗ «Газель» | 1 107 926,16 | 15,73 |
| УАЗ | 1 107 472,96 | 14,08 |
| FIAT | 1 110 820,46 | 11,88 |
| Peugeot Boxer | 1 115 970,46 | 11,47 |
| Ford Transit | 1 116 227,96 | 16,08 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 1 131 053,31 | 21,60 |

___________________________

2-нче номерлы кушымта

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 10 сентябрендәге
119 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

## Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында
## Нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча хезмәт күрсәтү (алга таба – хезмәт күрсәтү) бәясен исәпләү механизмын билгели.

1.2. Хезмәт күрсәтү бәясе хезмәт күрсәтү бәясе нормативы нигезендә, автотранспорт чарасы саны һәм хисап чорында автотранспорт чараларының факттагы йөреше буенча исәпләнә.

1.3. Хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары, ел саен, Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда, автотранспорт чараларының факттагы йөреше турындагы мәгълүмат, Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы белешмәләре буенча, автотранспорт чарасы маршрутының расланган паспорты кысаларында башкарылган хисап елында автотранспорт чарасының факттагы йөреше буларак кабул ителә.

### 2. Хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

1. *i* муниципаль берәмлек хезмәтен күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

2

$$S_i = \sum_{m=1}^{k}(n_{f_m} \times \mathrm{NF}_{\mathrm{km}_m} + \mathrm{NF}_{\mathrm{as}_m} M_m),$$

кайда:

$S_i$ – хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f_m}$ – m модельле автотранспорт чараларының факттагы юл узуы, километрларда;

$\mathrm{NF}_{\mathrm{km}_m}$ –гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру бәясе нормативының бер километрга ставкасы, сумнарда;

$\mathrm{NF}_{\mathrm{as}_m}$ – гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда бер автотранспорт чарасына йөртүне оештыру бәясе нормативы ставкасы, сумнарда;

$M_m$ – m модельле автотранспорт чаралары саны, берәмлектә;

$m$ – муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе номеры;

$k$ – муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләренең саны.

---